**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О науке и научной деятельности»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
29 октября 2020 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 18 июня 1998 года № 1661 «О науке и научной деятельности» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 7; 2006, № 5; 2014, № 6 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 3 (часть I) следующие изменения:

1) статью 2 изложить в следующей редакции:
«Статья 2. **Основные понятия, используемые в настоящем Законе**

1. Для целей настоящего Закона под государственной политикой Республики Татарстан в сфере науки понимается составная часть социально-экономической политики Республики Татарстан, которая выражает отношение государства к научной деятельности, определяет принципы, направления, формы деятельности органов государственной власти Республики Татарстан в сфере науки и реализации научных результатов и продукции.
2. Иные понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в том же значении, что и в Федеральном законе от 23 августа 1996 года № 127-ФЗ «О науке и государственной научно-технической политике».»;

2) в статье 3:
а) в наименовании слова «, совместные научно-исследовательские центры, лаборатории и временные творческие коллективы» исключить;
б) пункты 5, 6 признать утратившими силу;
в) пункт 7 изложить в следующей редакции:
«7. Государственные образовательные организации высшего образования, одной из уставных целей деятельности которых является научная деятельность,

осуществляющие деятельность на территории Республики Татарстан, и негосударственные научные организации вправе участвовать в обсуждении государственных научных программ и проектов, проведении их экспертизы, а также на основе конкурсов в выполнении научных программ, проектов за счет средств бюджета Республики Татарстан.»;

3) абзац пятый пункта 2 статьи 4 изложить в следующей редакции:

«Руководитель научной организации назначается (избирается) в соответствии с законодательством и в порядке, предусмотренном ее уставом, и несет ответственность за руководство научной, научно-технической, организационно-хозяйственной деятельностью научной организации, а также за реализацию программы или плана развития научной организации.»;

4) в статье 7:

а) в пункте 2 слова «является самоуправляемой организацией, действующей» заменить словами «является государственным научным бюджетным учреждением, действующим», слова «и профессионального» исключить;

б) в пункте 4 слова «в соответствии с законодательством» заменить словами «Кабинетом Министров Республики Татарстан»;

5) пункт 1 статьи 8 изложить в следующей редакции:

«1. Научным работником (исследователем) является гражданин, обладающий необходимой квалификацией и профессионально занимающийся научной и (или) научно-технической деятельностью.»;

6) в статье 11:

а) пункты 4, 5 признать утратившими силу;

б) пункт 6 изложить в следующей редакции:

«6. Научным работникам предоставляются меры социальной поддержки, предусмотренные нормативными правовыми актами Российской Федерации и нормативными правовыми актами Республики Татарстан.»;

7) в статье 12:

а) в наименовании слова «цели и» исключить;

б) пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2. Государственная политика Республики Татарстан в сфере науки осуществляется на следующих принципах:

а) признание науки социально значимой отраслью, определяющей уровень развития производительных сил государства;

б) гласность и использование различных форм общественных обсуждений при выборе приоритетных направлений развития науки, технологий и техники и экспертизе научных и научно-технических программ и проектов, реализация которых осуществляется на основе конкурсов;

в) гарантия приоритетного развития фундаментальных научных исследований;

г) интеграция науки и образования на основе различных форм участия работников и обучающихся образовательных организаций высшего образования в научных исследованиях и экспериментальных разработках посредством создания лабораторий в образовательных организациях высшего образования, кафедр на базе научных организаций;

д) поддержка конкуренции и предпринимательской деятельности в области науки и техники;

е) концентрация ресурсов на приоритетных направлениях развития науки, технологий и техники;

ж) стимулирование научной, научно-технической и инновационной деятельности через систему экономических и иных льгот;

з) развитие научной, научно-технической и инновационной деятельности посредством создания системы государственных научных центров и других структур;

и) развитие международного научного и научно-технического сотрудничества Республики Татарстан.»;

8) в статье 14:

а) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1. Финансовое обеспечение научной, научно-технической и инновационной деятельности основывается на его целевой ориентации и множественности источников финансирования и может осуществляться Республикой Татарстан, муниципальными образованиями, а также физическими лицами и (или) юридическими лицами способами, не противоречащими законодательству Российской Федерации и законодательству Республики Татарстан.»;

б) в пункте 3 слова «республиканские научные, научно-технические и инновационные программы и проекты» заменить словами «научные, научно-технические и инновационные программы и проекты Республики Татарстан».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
19 ноября 2020 года
№ 74-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» 1998 елның 18 июнендәге 1661 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2006, № 5; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2 статья. **Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр**

1. Әлеге Закон максатларында фән өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте дигәндә фәнни эшчәнлеккә карата дәүләт мөнәсәбәтен күрсәтә торган, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының фән һәм фәнни нәтиҗәләрне һәм продукцияне гамәлгә ашыру өлкәсендә эшчәнлегенең принципларын, юнәлешләрен һәм рәвешләрен билгели торган социаль-икътисадый сәясәтнең состав өлеше аңлашыла.

2. Әлеге Законда кулланылучы башка төшенчәләр «Фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте турында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль законда мәгънәләрендә кулланыла.»;

2) 3 статьяда:

а) исемендә «, уртак фәнни-тикшерену үзәкләре, лабораторияләре һәм вакытлы иҗади коллективлар» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 5, 6 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

в) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Эшчәнлекләренең устав максатларының берсе фәнни эшчәнлек булган, эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмалары һәм дәүләткә карамаган фәнни оешмалар

дәүләт фәнни программалары һәм проектлары буенча фикер алышуларда, аларга экспертиза үткәрүдә, шулай ук конкурслар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән фәнни программалар, проектлар үтәүдә катнашырга хокуклы.»;

3) 4 статьяның 2 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фәнни оешманың җитәкчесе законнар нигезендә һәм үз уставында каралган тәртиптә билгеләнеп куела (сайлана) һәм фәнни оешманың фәнни, фәнни-техник, оештыру-хуҗалык эшчәнлеге белән җитәкчелек итү, шулай ук фәнни оешманың үсеш программасын яисә планын гамәлгә ашыру өчен җаваплы була.»;

4) 7 статьяда:

а) 2 пунктта «, мөстәкыйль идарә итүче оешмадан гыйбарәт» сүзләрен «дәүләт фәнни бюджет учреждениесе булып тора» сүзләренә алмаштырырга, «, һөнәри» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 4 пунктта «законнар нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

5) 8 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кирәкле квалификациягә ия булган, фәнни һәм (яисә) фәнни-техник эшчәнлек белән һөнәри шөгыльләнүче граждан фәнни хезмәткәр (тикшеренүче) була.»;

6) 11 статьяда:

а) 4, 5 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Фәнни хезмәткәрләргә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган социаль ярдәм чаралары күрсәтелә.»;

7) 12 статьяда:

а) исемендә «максатлары һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Фән өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте түбәндәге принциплар буенча тормышка ашырыла:

а) фәнне дәүләтнең җитештерү көчләренең үсеш дәрәҗәсен билгели торган социаль әһәмиятле тармак дип тану;

б) фән, технологияләр һәм техника үсешенең өстенлекле юнәлешләрен сайлаганда һәм конкурс нигезендә тормышка ашырыла торган фәнни, фәнни-техник программаларга һәм проектларга экспертиза ясаганда һәркем өчен ачык булу һәм җәмәгать фикер алышуларының төрле рәвешләреннән файдалану;

в) фундаменталь фәнни тикшеренүләрне өстенлекле үстерүнең гарантияләнүе;

г) югары белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең һәм белем алучыларының фәнни тикшеренүләрдә һәм эксперименталь уйлап табуларда

катнашуының төрле рәвешләре нигезендә югары белем бирү мәгариф оешмаларында лабораторияләр, фәнни оешмалар базасында кафедралар төзү юлы белән фән һәм мәгариф интеграциясе;

д) фән һәм техника өлкәсендә конкуренциягә һәм эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итү;

е) фән, технологияләр һәм техника үсешенең өстенлекле юнәлешләрендә ресурсларны концентрацияләү;

ж) фәнни, фәнни-техник, инновацион эшчәнлекне икътисадый һәм башка ташламалар системасы аша кызыксындыру;

з) фәнни, фәнни-техник, инновацион эшчәнлекне дәүләт фәнни үзәкләре системасын һәм башка структураларны төзү юлы белән үстерү;

и) Татарстан Республикасының халыкара фәнни һәм фәнни-техник хезмәттәшлеген үстерү.».

8) 14 статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Фәнни, фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлекне финанс белән тәэмин итү аның максатчан юнәлешенә һәм финанслау чыганакларының күплегенә нигезләнә һәм Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган ысуллар белән Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекләр, шулай ук физик затлар һәм (яисә) юридик затлар тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.»;

б) 3 пунктта «фәнни, фәнни-техник һәм инновацион республика программалары һәм проектлары» сүзләрен «Татарстан Республикасының фәнни, фәнни-техник һәм инновацион программалары һәм проектлары» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 19 ноябрь
№ 74-ТРЗ